БАЛТАСИНСКИЙ
РАЙОННЫЙ СОВЕТ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН
РЕСПУБЛИКАСЫ
БАЛТАЧ РАЙОН СОВЕТЫ

**РЕШЕНИЕ**
15 марта 2021 г.

**КАРАР**
№42

**Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы территориясендә тышкы реклама һәм мәгълүмат чараларын урнаштыру тәртибе турындагы Нигезләмәне раслау хакында**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законга, «Реклама турында» 2006 елның 13 мартындагы 38-ФЗ номерлы Федераль законга, «Дәүләт контролен (күзәтчелеген) һәм муниципаль контрольне гамәлгә ашырганда юридик затларның һәм шәхси эшкуарларның хокукларын яклау турында» 2008 елның 26 декабрендәге 294-ФЗ номерлы Федераль законга, Татарстан Республикасы «Балтач муниципаль районы» муниципаль берәмлеге Уставына таянып, Балтач муниципаль районының бердәм архитектура-сәнгать йөзен формалаштыру, тышкы реклама һәм мәгълүмат (реклама конструкцияләре) чараларын урнаштыруны тәртипкә салу һәм гадиләштерү, рөхсәт документларын әзерләү процедурасына чыгымнарны киметү, реклама конструкцияләрен һәм тышкы мәгълүмат чараларын урнаштырганда һәм эксплуатацияләгәндә мөлкәттән нәтиҗәле файдалануны, район халкының иминлеген тәэмин итү максатыннан Балтач район Советы карар бирде:

1. Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы территориясендә тышкы реклама һәм мәгълүмат чараларын урнаштыру тәртибе турындагы Нигезләмәне 1 нче кушымта нигезендә расларга.

2. Әлеге карарны «Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталы» интернет - ресурсында бастырып чыгарырга һәм Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре порталы составында Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районының рәсми сайтында (baltasi.tatarstan.ru) урнаштыру юлы белән халыкка җиткерергә.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Балтач район башкарма комитеты җитәкчесенә йөкләргә.

Балтач муниципаль районы башлыгы,
Балтач район Советы рәисе

Р. Р. Нотфуллин

Татарстан Республикасы
Балтач район Советының
2021 елның «15» марты
42 номерлы карарына
1 нче кушымта

**Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы территориясендә тышкы реклама һәм мәгълүмат чараларын урнаштыру тәртибе турындагы Нигезләмә**

## 1. ГОМУМИ НИГЕЗЛӘМӘЛӘР

1.1. Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы территориясендә тышкы реклама һәм мәгълүмат чараларын урнаштыру тәртибе турындагы (алга таба - нигезләмә) әлеге Нигезләмә Россия Федерациясенең һәм Татарстан Республикасының гамәлдәге Законнары, Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы Уставы нигезендә эшләнде. Нигезләмә рөхсәт документациясен проектлауга, рәсмиләштерүгә һәм килештерүгә, реклама конструкцияләрен һәм мәгълүмат чараларын урнаштыруга (монтажлауга, сүтүгә), эксплуатацияләүгә, шулай ук муниципаль милектәге транспорт чараларына реклама урнаштыруга һәм әлеге таләпләрнең үтәлешен контрольдә тотуга Балтач муниципаль районы өчен бердәм тәртип һәм таләпләр билгели.

1.2. Әлеге Нигезләмә оештыру-хокукый формаларына һәм милек формаларына бәйсез рәвештә барлык берләшмәләргә, предприятиеләргә, учреждениеләргә һәм оешмаларга, шәхси эшкуарларга, шулай ук Балтач муниципаль районы территориясендә реклама конструкцияләрен урнаштыру һәм эксплуатацияләү эшчәнлегендә катнашучы физик затларга кагыла.

1.3. Әлеге Нигезләмә максатларында түбәндәге төп төшенчәләр кулланыла:

1) реклама - теләсә нинди ысул белән, теләсә нинди формада һәм теләсә нинди чаралардан файдаланып, билгесез затлар даирәсенә адресланган һәм реклама объектына игътибарны җәлеп итүгә, аңа карата кызыксыну формалаштыруга яки кызыксынуны саклауга һәм аны базарга чыгаруга юнәлтелгән мәгълүмат;

2) реклама объекты - реклама ярдәмендә аңа игътибар җәлеп ителергә тиешле товар, юридик затның һәм (яки) товарның индивидуальләшүе чаралары, товарның җитештерүчесе яки сатучысы, интеллектуаль эшчәнлек нәтиҗәләре яки чара (шул исәптән спорт ярышы, концерт, конкурс, фестиваль, рискка нигезләнгән уеннар, пари);

3) товар - сату, алмашу яисә башка әйләнешкә кертү өчен билгеләнгән эшчәнлек продукты (шул исәптән эш, хезмәт күрсәтү);

4) тиешле булмаган реклама - Россия Федерациясе законнары таләпләренә туры килми торган реклама;

5) реклама бирүче - товарны җитештерүче яки сатучы яисә рекламалау объектын һәм (яки) реклама эчтәлеген билгеләгән бүтән зат;

6) реклама җитештерүче - мәгълүматны тулысынча яисә өлешчә реклама рәвешендә тарату өчен әзер формага китерүче зат;

7) реклама таратучы - теләсә нинди ысул белән, теләсә кайсы формада һәм теләсә нинди чаралардан файдаланып, реклама таратуны гамәлгә ашыручы зат;

8) реклама кулланучылары - аларның игътибарын реклама объектына җәлеп итүгә юнәлдерелгән затлар;

9) иганәче - спорт, мәдәни яисә теләсә нинди башка чараны оештыру һәм (яисә) уздыру, теле- яисә радиотапшыруларны булдыру һәм (яисә) трансляцияләү яки иҗат эшчәнлегенең башка нәтиҗәсен булдыру һәм (яисә) файдалану өчен акчалар биргән яисә акчалар бирүне тәэмин иткән зат;

10) иганәчелек рекламасы - анда һичшиксез иганәче буларак билгеле бер зат турында

мәҗбүри рәвештә искә алу шартларында таратыла торган реклама;

11) социаль реклама - теләсә нинди ысул белән, теләсә нинди формада һәм затларның билгесез даирәсенә адресланган һәм хәйрия һәм башка иҗтимагый файдалы максатларга ирешүгә, шулай ук дәүләт мәнфәгатьләрен тәэмин итүгә юнәлдерелгән теләсә нинди чаралар кулланып таралган мәгълүмат;

12) тышкы мәгълүмат чарасы - реклама булмаган тышкы мәгълүматны таратуда кулланыла торган тотрыклы территориаль урнаштыру техник җайланмасы;

реклама конструкциясе — тышкы реклама таратуда кулланыла торган тотрыклы территориаль урнаштыру техник җайланмасы.

14) реклама конструкциясен, тышкы мәгълүмат чараларын урнаштыру урыны - реклама конструкцияләре, тышкы мәгълүмат чаралары урнаштырыла торган территория, бина, төзелеш, корылма яисә бинаның, төзелешнең, корылманың бер өлеше, башка объектлар;

15) реклама конструкциясе хуҗасы (физик яисә юридик зат) - реклама конструкциясе милекчесе яисә реклама конструкциясенә әйбер хокукы булган яисә хуҗасы белән шартнамә нигезендә реклама конструкциясенә ия булу һәм аннан файдалану хокукы булган башка зат;

16) Реклама таратучы - тышкы реклама таратучы зат;

17) реклама конструкциясенең мәгълүмат кыры - реклама характерындагы мәгълүматны үз эченә алган реклама конструкциясенең бер өлеше.

1.4. Әлеге Нигезләмә түбәндәгеләргә кагылмый:

1) сәяси реклама, шул исәптән сайлау алды агитациясе һәм референдум мәсьәләләре буенча агитация;

2) федераль закон нигезендә аны ачу яисә тарату яки кулланучыга җиткерү мәҗбүри булган мәгълүмат;

3) мәгълүмати-белешмә һәм аналитик материаллар (эчке һәм тышкы базарларны күзәтү, фәнни тикшеренүләр һәм сынаулар нәтиҗәләре), төп максаты товарны базарда сатуны алга сөрү һәм социаль реклама булмаган материаллар;

4) әгәр мондый хәбәрләр реклама характерындагы белешмәләр булмаса һәм социаль реклама булмаса, дәүләт хакимияте органнары, башка дәүләт органнары хәбәрләре, җирле үзидарә органнары хәбәрләре, җирле үзидарә органнарына кермәгән муниципаль органнар хәбәрләре;

5) реклама характерындагы белешмәләре булмаган элмәтакталар һәм күрсәткечләр;

6) эшкуарлык эшчәнлеген гамәлгә ашыруга бәйле булмаган физик затларның яисә юридик затларның игъланнары;

7) товарга яисә аның төргәгенә урнаштырылган товар турында, аны әзерләүче турында, импортер яисә экспортер турында мәгълүмат;

8) товарга яисә аның төргәгенә урнаштырылган һәм башка товарга карамаган товарны бизәүнең теләсә нинди элементлары;

9) фән, әдәбият яисә сәнгать әсәрләренә табигый рәвештә интеграцияләнгән һәм үзләре реклама характерындагы белешмәләр булып тормаган товар, аның индивидуальләштерү чаралары, товарны җитештерүче яисә сатучы турында искә алу.

## 2. Идарә һәм контроль органнары

2.1. Реклама конструкцияләрен һәм мәгълүмат чараларын проектлау һәм урнаштыру, бердәм район реклама-мәгълүмат киңлекләрен булдыру, реклама конструкцияләрен инвентаризацияләү,расланган проект документациясенең билгеләнгән реклама конструкцияләренә туры килүен контрольдә тотуны Татарстан Республикасы Балтач район башкарма комитеты (алга таба – Район башкарма комитеты) гамәлгә ашыра.

2.2. Реклама конструкциясе паспортын, реклама конструкцияләренең тышкы кыяфәтен, реклама конструкциясе астындагы җир кишәрлегенең торышын Район башкарма комитетының төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалык бүлеге башлыгы урынбасары (баш архитектор) килештерә.

## 3. Районда урнаштырыла торган реклама һәм мәгълүмат

3.1. Районда урнаштырыла торган реклама һәм мәгълүмат түбәндәге төрләргә бүленә:

Балтач муниципаль районының җирле үзидарә органнары һәм муниципаль

учреждениеләре мәгълүматы, социаль реклама, реклама.

Мәгълүмат чарасын реклама дип күрсәтү реклама конструкциясен теркәү зарурлыгына китерә.

3.2. Балтач муниципаль районының җирле үзидарә органнары һәм муниципаль учреждениеләре мәгълүматына түбәндәгеләр керә:

3.2.1. Район һәм федераль структураларга, махсус һәм оператив хезмәтләргә карауларын күрсәтә торган төсле график схемалар, тану билгеләре, транспорт чараларында язулар (ЮХИДИ бүлеге, Россия Федерациясе Эчке эшләр министрлыгы бүлеге, янгын сагы, ашыгыч ярдәм һ. б.);

3.2.2. Мәгълүмати ориентлашу күрсәткечләре: урам исемнәре, биналарның номерлары, пассажир транспорты хәрәкәте расписаниеләре;

3.2.3. Куркынычсызлык һәм халыкка мәгълүмат җиткерү максатларында урнаштырыла торган төзелеш, юл, авария һәм башка эшләр башкару турында мәгълүмат;

3.2.4. Район инфраструктурасы объектлары: архитектура ансамбльләре, бакча-парк комплекслары, аерым биналар һәм корылмалар турында мәгълүмат;

3.2.5. Мәдәният, мәгариф һәм сәламәтлек саклау учреждениеләренең үзләренә караган конструкцияләрдә урнаштырыла торган аларның эшчәнлеге юнәлеше буенча мәгълүматы, шул исәптән театрлар һәм кинотеатрлар репертуарлары (театр һәм кино афишалары) турында мәгълүмат;

3.2.6. Районның бәйрәм бизәлеше - төрле декоратив элементлар (йомшак тартып бәйләнгән бизәлеш, флаглар, яктылык җайланмалары, тарткычлар, панно, гирляндалар һ.б.) Балтач муниципаль районы башлыгының хокукый акты нигезендә тематик планнар буенча башкарыла.

Балтач муниципаль районының җирле үзидарә органнары һәм муниципаль учреждениеләре мәгълүматы реклама булып тормый һәм аны тарату реклама турындагы законнар белән җайга салынмый.

Балтач муниципаль районының җирле үзидарә органнары һәм муниципаль учреждениеләре мәгълүматын урнаштырган өчен түләү алынмый.

Балтач муниципаль районының җирле үзидарә органнары һәм муниципаль учреждениеләре мәгълүматы әлеге Нигезләмәнең 4 пункты таләпләренә җавап бирергә тиешле төрле конструкцияләрдә урнаштырыла.

Балтач муниципаль районы җирле үзидарә органнары һәм муниципаль учреждениеләр мәгълүматын плакатлар, афишалар рәвешендә әлеге максат өчен җиһазланмаган биналарда, коймаларда, терәүләрдә, корылмаларда һәм башка урыннарда урнаштыру рөхсәт ителми.

3.3. Реклама предприятиеләрне һәм оешмаларны мәгълүмати бизәүне үз эченә алмый.

Предприятиеләр һәм оешмаларның мәгълүмати бизәлешенә түбәндәге мәгълүмат керә:

3.3.1. Предприятиенең профиле, аның фирма атамасы һәм теркәлгән товар билгесе (элмә такта) турында мәгълүмат.

Элмә такта кулланучыга «Кулланучылар хокукларын яклау турында» Федераль закон нигезендә җитештерүче (башкаручы, сатучы) турында мәгълүматны җиткерү өчен билгеләнгән.

Элмә такта предприятие тарафыннан милек хокукында яки бина милекчесе белән килешү буенча аренда хокукларында биләнә торган биналар чикләрендә урнашырга тиеш. Элмә такта стена панносы, кронштейн, маркизалар, тулысынча предприятие урнашканда бинада-тәүлекнең караңгы вакытында яктыртылган түбә җайланмасы рәвешендә эшләнергә мөмкин.

Элмә тактада предприятиенең профилен һәм аның исемен ача торган мәгълүмат булырга тиеш. Элмә тактада билгеләнгән тәртиптә теркәлгән товар билгеләре, логотиплар һәм әлеге предприятиегә хезмәт күрсәтү билгеләре, шулай ук декоратив элементлар урнаштырырга мөмкин. Элмә тактага урнаштырылган башка мәгълүмат реклама булып санала.

Элмә тактадагы хәрефләрнең биеклеге 0,15 м дан да ким булмаска тиеш. Элмә тактадагы текстлар Татарстан Республикасының рәсми телләрендә эшләнергә тиеш.

Текстларда рус хәрефләре белән язылган чит ил сүзләрен, ә предприятие профилен билгеләгәндә - кыскартулар һәм аббревиатуралар кулланырга ярамый.

Чит ил фирмаларының, шулай ук устав фондында чит ил фирмалары катнашкан Россия предприятиеләренең - рәсми вәкилләрнең (дилерларның яки дистрибьюторларның) теркәлгән товар билгеләре яисә хезмәт күрсәтү билгеләре, рус телендә язылышы булмаган очракларда, оригиналь рәвештә язылырга мөмкин. Шул ук вакытта товар билгеләрен һәм хезмәт күрсәтү билгеләрен язудагы хәрефләрнең биеклеге һәм киңлеге предприятие профилен ача торган төп текстка караганда ким дигәндә ике тапкырга кимрәк булырга тиеш.

Товар билгеләре һәм хезмәт күрсәтү билгеләре сурәтләренең саны һәм гамәлгә ашыру ысуллары предприятие профилен ачучы тексттан өстен булырга тиеш түгел.

Барлык элмә такталарны Район башкарма комитетының төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалык бүлеге башлыгы урынбасары (баш архитектор) килештерә һәм ул әлеге предприятиенең фасады паспортына мәҗбүри кертелергә тиеш.

3.3.2. Мәгълүмат табличкалары, учреждение такталары.

Мәгълүмат тактасы (мәҗбүри элмә такта) кулланучыга «Кулланучылар хокукларын яклау турында» Федераль закон нигезендә җитештерүче (башкаручы, сатучы) турында мәгълүмат җиткерү өчен билгеләнгән.

Хезмәт күрсәтүнең һәр предприятиесендә халык өчен керү саны буенча бер яки берничә мәгълүмат табличкасы булырга тиеш. Табличкада предприятие турында түбәндәге мәҗбүри мәгълүмат күрсәтелергә тиеш:

- предприятиенең теркәлгән (юридик) исеме;
- оештыру-хокукый форма;
- предприятиенең эш режимы;
- реклама булмаган характердагы өстәмә мәгълүмат (кирәк булган очракта).

Мәгълүмат табличкалары предприятиегә керү урыны янында яки керү ишегендә аларны килүчеләр яхшы күрерлек итеп урнаштырылырга тиеш. Мәгълүмат табличкалары витрина пыяласында, керү ишекләрендә һәм башкаларда язулар белән алыштырылырга мөмкин.

Мәгълүмат табличкасы 0,3 кв.м. дан 0,7 кв.м га кадәр үлчәмдә булырга тиеш. Тексттагы хәрефләрнең биеклеге 3 см дан ким булмаска тиеш.

Мәгълүмат табличкалары рөхсәт документлары белән рәсмиләштерелергә тиеш түгел.

Учреждение такталары мәҗбүри тәртиптә оешмага (учреждениега) кергәндә урнаштырылырга тиеш. Учреждение тактасында оешманың тулы теркәлгән (юридик) исеме һәм аның кайсы ведомствога каравы турында мәгълүмат булырга тиеш. Учреждение тактасы 0,3 кв.м. дан 1,5 кв. м га кадәр булырга тиеш. Тексттагы хәрефләрнең биеклеге 3 см дан ким булмаска тиеш.

3.3.3. Витриналарда урнаштырылган мәгълүмат.

Хезмәт күрсәтү өлкәсе предприятиеләре витринасында түбәндәгеләрне урнаштырырга рөхсәт ителә:

әлеге предприятиедә сатыла торган товарлар һәм күрсәтелүче хезмәтләр, шул исәптән товар продукциясе үрнәкләре турында мәгълүмат;

предприятиенең үз яисә фирма исеме (әгәр ул бар икән), аның теркәлгән товар билгеләре һәм хезмәт күрсәтү билгеләре;

предприятиенең профилен ача торган һәм аның фирма исеменә туры килә торган рәсем элементлары;

декоратив бизәлеш элементлары;

дәүләт һәм шәһәр бәйрәмнәренә урнаштырыла торган бәйрәм бизәлеше.

Витринада урнаштырылган югарыда күрсәтелгән мәгълүматны, әгәр ул сәүдә маркалары, исемнәре, товар билгеләре һәм башка фирмаларның хезмәт күрсәтү билгеләре булмаса, рөхсәт документациясе белән рәсмиләштерү кирәкми.

Витрина өстенә (аны ябып) мәгълүмат урнаштыру рөхсәт ителми.

3.4. Социаль рекламада товарларның конкрет маркалары (модельләр, артикуллар), товар билгеләре, хезмәт күрсәтү билгеләре һәм аларны индивидуальләштерүнең башка

чаралары турында, физик затлар һәм юридик затлар турында искә алу рөхсәт ителми. Күрсәтелгән чикләүләр дәүләт хакимияте органнары, башка дәүләт органнары, җирле үзидарә органнары турында, җирле үзидарә органнары структурасына керми торган муниципаль органнар турында, иганәчеләр турында, әлеге статьяда билгеләнгән таләпләргә туры килә торган социаль юнәлешле коммерциягә карамаган оешмалар турында, шулай ук аларга хәйрия ярдәме күрсәтү максатларында, авыр тормыш хәлендә калган яки дәвалауга мохтаҗ физик затлар турында искәртмәләргә кагылмый. Әгәр бу реклама эчтәлеге мондый коммерциягә карамаган оешмаларның хәйрия яисә башка иҗтимагый файдалы максатларга ирешүгә юнәлдерелгән эшчәнлеге турындагы мәгълүмат белән турыдан-туры бәйле булса, социаль рекламада социаль юнәлешле коммерциягә карамаган оешмалар турында искә алу рөхсәт ителә.

**Реклама конструкцияләре һәм тышкы мәгълүмат чаралары**

Реклама конструкцияләре түбәндәге төрләргә бүленә:

стационар - бер типтагы яисә стандарт булмаган башкаруда җайланманың һәм конструкциянең үзгәрешсез урыны белән характерлана;

вакытлы - күрсәтелгән чорга билгеләнергә мөмкин булган урнаштыру чоры һәм билгеләнгән зона яисә шәһәр территориясе участогы белән характерлана;

транспорттагы реклама - мәгълүмат кулланучыга карата хәрәкәт иткәндә аңа шәһәрнең төрле өлешләрендә йогынты ясавы белән характерлана, мәгълүмат урнаштыру өчен билгеләнгән транспорт чарасының бер өлеше яисә транспорт чарасына төшерелгән сурәт булып тора;

реклама-тамаша чаралары - хәрәкәт (йөреш) маршруты һәм/яки үткәрелү урыны (митинглар, акцияләр) һәм хәбәр ителгән катнашучылар саны белән характерлана.

Реклама конструкциясенең мәгълүмат кыры - реклама урнаштыру өчен билгеләнгән реклама конструкциясенең бер өлеше.

4.1. Стационар реклама конструкцияләре һәм аларны урнаштыруга куелган таләпләр.

4.1.1. Стационар реклама конструкцияләренә даими урнаштыру урыны булган реклама хәбәрләре йөртүчеләре керә.

Стационар реклама конструкцияләре түбәндәге төрләргә бүленә:

- аерым торучы;

- биналарда, корылмаларда һәм шәһәрне төзекләндерү элементларында урнаштырылган.

4.1.2. Стационар реклама конструкцияләренә гомуми таләпләр:

- аларның конструкциясе гамәлдәге төзелеш нормалары һәм кагыйдәләре нигезендә, җир эшләрен башкаруга ордер рәсмиләштереп проектланган, әзерләнгән һәм монтажланган булырга тиеш;

- стационар реклама конструкцияләре мәгълүмат хәбәрләреннән башка файдаланылырга тиеш түгел;

- аерым торучы реклама конструкцияләренең хуҗасы һәм аның телефон номеры күрсәтелгән маркировкасы булырга тиеш. Маркировка мәгълүмат кыры астында урнашырга тиеш. Текстның размеры аны транспорт чаралары хәрәкәтенең якындагы полосасыннан укырлык булырга тиеш;

- реклама конструкцияләрен яктырту өчен сәнәгать җитештерүенең электр һәм янгын куркынычсызлыгы таләпләрен үтәүне тәэмин итүче яктылык приборлары кулланылырга тиеш. Яктылык приборын ныгыту аның реклама конструкциясе белән ышанычлы тоташуын тәэмин итәргә, җил һәм кар йөкләнешенә, тирбәлеш һәм бәрмә йогынтыларга бирешмәскә тиеш;

- реклама конструкцияләренең терәүләре аларга килеп бәрелгәндә югары иминлек дәрәҗәсен, җил йөкләнеше вакытында һәм эксплуатацияләгәндә җитәрлек тотрыклылыкны тәэмин итүче материаллардан эшләнергә тиеш.

4.1.3. Реклама конструкцияләрен урнаштыруга гомуми таләпләр:

- реклама конструкцияләрен урнаштыру Төзелеш нормалары һәм кагыйдәләре (СНиП) 2.07.01-89* һәм Дәүләт стандарты (ГОСТ) Р 52044-2003 нигезендә гамәлгә ашырыла;

- стационар реклама конструкцияләре яисә аларның аерым өлешләре хәрәкәт полосасы өстеннән 5 метрдан түбән урнаша алмый. Инженерлык корылмалары өслегендә урнаштырыла торган реклама конструкцияләре искәрмә була ала;

- стационар реклама конструкцияләре яисә аларның аерым өлешләрен борт ташы булмаган юллардан читтәге юлның җир полотносыннан 3 метрга якын урнаштыру рөхсәт ителми;

- реклама конструкцияләре җәяүлеләргә йөрү өчен, урамнарны һәм тротуарларны механикалаштырылган җыештыру өчен киртәләр тудырырга тиеш түгел;

- торак биналар янында тавыш, вибрация, көчле яктылык, электр магниты һәм башка нурланышлар һәм кырлар чыганаклары булган стационар реклама конструкцияләрен урнаштыру рөхсәт ителми;

- сәнгать һәм тарихи кыйммәткә ия биналарда һәм корылмаларда, дәүләт тарафыннан саклана торган архитектура һәйкәлләрендә, шулай ук биналар стеналарында урнаштырылган мемориаль такталар янында реклама конструкцияләре урнаштыру рөхсәт ителми.

4.1.4. Аерым торучы стационар реклама конструкцияләренең типлары:

4.1.4.1. Щитлы җайланмалар - мәгълүмат урнаштыру өчен тышкы өслеге булган һәм нигез, каркас һәм мәгълүмат кырыннан торган аерым торучы конструкцияләр.

Бер типтагы щитлы җайланмалар мәгълүмат кырының күләмнәре буенча түбәндәге төрләргә бүленә:

- зур форматтагы щит конструкцияләре (2 x 3 м, 3 x 6 м зуррак);

- кече (шәһәр) форматындагы щит конструкцияләре (1,8 x 1,2 м һәм кимрәк).

Щитлы җайланмаларга таләпләр:

- щитлы җайланмалар, кагыйдә буларак, ике яклы вариантта башкарыла;

- икенче ягы декоратив бизәлешле берьяклы вариантта эшләнгән щитлы җайланмалар;

- аерым торучы җайланмаларның нигезе җир өсте тигезлегеннән чыгып тормаска яисә декоратив бизәлешле булырга тиеш;

- визуаль кабул итүне боза торган катылыкның конструктив элементлары һәм ныгытмалар (болт тоташтыргычлары, терәү элементлары, технологик косынкалар һ.б.) декоратив элементлар белән ябылырга тиеш;

- щитлы җайланмаларда конструкцияләрнең төрле өлешләрендәге күзгә күренерлек тоташтыргыч элементлары (конструкцияләрнең торц өслекләре, яктырту арматурасы ныгытмалары, нигез белән тоташтыргычлар) булмаска тиеш;

- щитлы җайланмалар мәҗбүри тәртиптә техник экспертиза узарга тиеш.

Щитлы җайланмалар арасындагы ераклык конкрет шәһәр төзелеше вәзгыяте белән билгеләнә, ләкин кимендә 100 м булырга тиеш, ә кече яки шәһәр форматындагы конструкцияләр өчен - кимендә 40 м.

Юл сервисы билгеләре һәм маршрут ориентлашу билгеләре (реклама билгеләре) - конструкцияләре Дәүләт стандарты (ГОСТ) 10807-78 таләпләре нигезендә проектланган һәм әзерләнгән щитлы җайланмалар.

Реклама билгеләре белән билгеләнергә мөмкин булган сервис объектларына хәрәкәттә катнашучыларга хезмәт күрсәтү өчен билгеләнгән тар профильле объектлар (кабымханәләр, автотехниканы ремонтлау предприятиеләре һ.б.) керә.

Реклама билгеләре 1000 мм киңлектә, 1500 мм биеклектә, төп фон сары һәм кара төстә (капма-каршылык булдыручы, контрастлаучы) - символлар һәм язулар; эчке (тышкы) яктылык яисә яктылыкны кире кайтара торган өслек белән. Реклама-мәгълүмат билгеләренең кире ягы соры төстә булырга тиеш.

Реклама билгеләре юл билгеләре белән бер кәүсәдә (створда) урнаштырыла алмый, шулай ук аларны күрү мөмкинлеген чикләргә яки транспорт чаралары йөртүчеләр һәм җәяүлеләр тарафыннан аларны кабул итүгә комачауларга тиеш түгел.

Юлны карап тотуның уңайлылыгын исәпкә алырга, шулай ук реклама билгеләренең транспорт чаралары белән очраклы рәвештә зыян күрүләрен булдырмаска кирәк.

4.1.4.2. Күләмле мәйданлы конструкцияләр - мәгълүмат урнаштыру өчен конструкция күләме дә, аның өслеге дә кулланыла торган тышкы реклама чаралары. Әлеге

конструкцияләр махсус проектлар буенча башкарыла.

4.1.4.3. Флаг композицияләре һәм асылма түбәләр - нигездән, бер яки берничә флагштоктан (стойка) һәм йомшак тукымадан торган тышкы реклама чаралары.

Флагларны яктырту баганасына, бинага һәм корылмага нигез итеп файдаланырга мөмкин.

4.1.4.4. Җир өслегендә урнаштырыла торган җир паннолары юл яки җир катламына ясалган яки урнаштырылган төзелеш материалларыннан тора һәм түбәндәге төрләргә бүленә:

трассалар һәм юл авышлыкларында (откосларда) каркас паннолары;

урамнарның тротуарларын төрле буяулы матдәләр яки пленка материаллары белән каплау;

юл-төзелеш материалларыннан ясалган урамнар тротуарларында панно.

Кулланыла торган материаллар тротуарлар катламын яки панно урнаштыруның башка урыннарын начарайтырга тиеш түгел.

4.1.4.5. Динамик реклама конструкцияләре.

Күппозицияле динамик реклама конструкциясе - мәгълүмат кыры бертигез күпкырлы призмалар җыелмасыннан барлыкка килгән тышкы яктырткычлы яссы реклама калканы рәвешендә эшләнгән электромеханик җайланма.

Роллер дисплей (скроллер) - эзлекле рәвештә билгеле вакыт аралыгында реклама хәбәрләрен күрсәтә торган барабаннар урнаштырылган, эчке яктыртулы реклама конструкциясе.

4.1.4.6. Электрон экран (электрон табло) - югары аеру сәләтенә, аз энергия куллануга, югары яктылыкка ия булган, бирелгән расписание буенча компьютер анимациясе һәм видеороликлар күрсәтү өчен билгеләнгән, шулай ук турыдан-туры видеотрансляция (тере видео) мөмкинлегенә ия булган реклама конструкциясе.

4.1.5. Биналарда, корылмаларда һәм шәһәрне төзекләндерү элементларында урнаштырылган стационар реклама конструкцияләре типлары:

4.1.5.1. Түбә җайланмалары - бина кәрнизеннән тулысынча яки өлешчә югарырак куела торган күләмле яки яссы конструкцияләр.

Түбә җайланмалары ныгыту элементларыннан, конструкциянең төп өлешеннән һәм мәгълүмат җайланмасыннан тора.

Түбә җайланмаларының мәгълүмат өлешләрен эчке яктырту белән, газ яктысы һәм җепселле-оптик элементлар, электрон табло кулланып әзерләү тәкъдим ителә.

Түбә җайланмаларының янгын сүндерү системасы булырга тиеш һәм авария хәлендә электр белән тәэмин итү челтәреннән сүндерү системасы белән җиһазланган булырга тиеш.

Түбә җайланмаларында җирдән гади күз белән күрә алырлык реклама конструкциясе хуҗасы күрсәтелгән табло булырга тиеш.

Ныгыту элементлары, шулай ук конструкциянең төп өлеше элементлары кире яктан декоратив панельле булырга тиеш.

Түбә җайланмасын урнаштыруга заявкалар конкрет заказчы өчен эшләнгән дизайн-проект һәм техник хезмәтләрнең башлангыч экспертизасы бәяләмәсе булганда кабул ителә.

4.1.5.2. Стена панносы - түбәндәге рәвештәге биналарның һәм корылмаларның стена яссылыкларында урнашкан реклама конструкциясе:

стенага турыдан-туры төшерелгән сурәтләр (мәгълүмат кыры);

Ныгыту элементларыннан, каркастан һәм мәгълүмат кырыннан торган конструкцияләр.

Стена паннолары бер типтагы яки махсус проектлар буенча башкарыла.

Ныгыту элементлары булган стена паннолары өчен мәҗбүри тәртиптә эксплуатацияләгәндә куркынычсызлыкны тәэмин итү максатыннан конструкцияне ныгыту проекты эшләнә.

Стена панносы хуҗасын һәм аның телефон номеры күрсәтелгән (идентификацияләнгән) маркировкалы булырга тиеш. Маркировка мәгълүмат кыры астында урнашырга тиеш.

4.1.5.3. Кронштейннар - үз терәүләренә, шәһәр яктыртуындагы мачта-терәүләрдә,

контакт челтәре терәүләрендә яки биналарда урнаштырыла торган ике яклы консоль яссы конструкцияләр.

Кронштейннар эчке яктырту белән ике яклы вариантта башкарылырга тиеш.

Терәүләрдә урнаштырылган кронштейннарның типлаштырылган зурлыгы (вертикаль башкаруда):

- 1,5 х 1,0 м; 1,2 х 1,0 м - проспектлар, мәйданнар, урамнар өчен;
- 1,0 х 0,7 м - тар урамнар һәм тыкрыклар өчен.

Биналарның фасадларында урнаштырылган кронштейннар күләме бинаның архитектур үзенчәлекләре белән билгеләнә һәм 1,5 х 1,0 м дан артмаска тиеш.

Электр челтәре терәүләрендә урнаштырылган кронштейннар конструкциянең аскы кырыеннан юл полотносына кадәр 3,3 м биеклектә урнаштырылырга тиеш. Кронштейннарның зурлыгы 1,0 х 1,5 метрдан артмаска тиеш.

Эксплуатацияләүдә куркынычсызлык максатларында кронштейннар җирдән кимендә 4,5 м биеклектә урнаштырылырга тиеш. Биналарда, кагыйдә буларак, кронштейннар беренче һәм икенче катлар арасында урнаштырыла.

Терәүгә куйганда, кронштейннар юлның йөрү өлешенә капма-каршы якка таба юнәлтелергә тиеш. Терәүгә бердән артык кронштейн урнаштыру рөхсәт ителми.

Биналарда һәм корылмаларда урнаштырылган кронштейннар бинага беркетү ноктасыннан 1,5 м читтә булырга тиеш.

Биналарда һәм корылмаларда кронштейн-күрсәткечләр кую рөхсәт ителми, предприятиеләр магистральдән турыдан-туры күренми торган шул ук бинада урнашкан очраклардан тыш.

4.1.5.4. Иҗтимагый транспортның тукталыш павильоннарында, киоскларда урнаштырылган һәм милекче белән яисә әлеге мөлкәткә әйбер хокуклары булган зат белән килештерелгән реклама конструкцияләре пыяла белән капланырга тиешле яссылыкта яисә павильон һәм киосклар түбәләрендә урнаштырылырга тиеш. Әлеге тип конструкцияләргә һәм аларны урнаштыру кагыйдәләренә аерым торучы щитлы конструкцияләргә карата куелган таләпләр (4.1.4.1 пункт) кагыла.

4.1.5.5. Транспарантлар - тарткычлар үз терәүләреннән, үз терәүләренә яки биналарның фасадына беркетү җайланмаларыннан, тартылу җайланмасыннан һәм мәгълүмати сурәттән тора. Шәһәр яктыртуы баганасында транспарантлар-тарткычлар урнаштыру рөхсәт ителә.

Транспарантлар-тарткычлар яктылык транспарантлары-тарткычларына (шул исәптән гирляндалар) һәм каты материаллардан һәм йомшак материаллардан ясалган яктыртылмаганнарга бүленә.

Яктылык транспарантлары-тарткычлары конструкциясендә авария хәлендә электр челтәрләреннән өзү җайланмасы булырга тиеш.

Күрше транспарантлар-тарткычлар арасында ара 75 метрдан да ким булмаска тиеш.

Транспарантлар-тарткычлар урамнарның машиналар йөрү өлеше өстеннән 7,5 м дан да түбәнрәк булырга тиеш түгел.

Транспарантлар-тарткычлар хуҗасы турындагы мәгълүмат табличкасы терәүдә яисә тартылу җайланмасында бинаның фасадына беркетелгән урынга якын урнашырга тиеш; текст размеры аны хәрәкәтнең иң чик уң полосасыннан күрә алырлык булырга тиеш.

Юл киртәләрендә, күпер кичүләре коймаларында һәм башкаларда транспарантлар-тарткычлар кую рөхсәт ителми.

Контакт челтәре терәүләрендә урнаштырыла торган транспарантлар йомшак тукымадан әзерләнергә тиеш; юл аша урнаштырыла торган транспарантлар киселгән булырга тиеш.

4.1.5.6. Витриналар - биналарның һәм корылмаларның пыяла уемнарында һәм биналарның витражларында урнаштырыла торган яисә аерым торучы конструкцияләр рәвешендәге күләмле тышкы реклама чаралары. Конструктив рәвештә витрина нигездән, каркастан һәм үтә күренмәле өслекләрдән тора.

Мәгълүмат витринаның эчке ягында урнаша.

Витриналарның тәүлекнең караңгы вакытында яктырткычлары булырга тиеш.

4.1.5.7. Проекция җайланмалары - җирдә, стеналар өслекләрендә һәм күләмле сурәт

ясау өчен билгеләнгән реклама конструкцияләре. Проекция җайланмаларының конструкцияләре проекция җайланмасыннан һәм өслегеннән (экраннан) яисә мәгълүмати сурәт формалаша торган күләмнән гыйбарәт.

4.1.5.8. Маркизлар - реклама мәгълүматы төшерелгән козыреклар һәм асылмалы түбәләр рәвешендә эшләнгән һәм биналарның һәм корылмаларның витриналары, керү урыны яки уемнары (проемнары) өстендә урнаштырыла торган реклама конструкцияләре. Маркизлар бинага беркетү элементларыннан, йомшак яки каты нигездә эшләнгән каркас һәм мәгълүмат кырыннан тора.

4.2. Вакытлы реклама конструкцияләре. Вакытлы реклама конструкцияләренә 1 елдан да ким вакытка урнаштыру шарты белән, шәһәр территориясенең билгеле бер участогында урнаштырыла торган реклама хәбәрләре йөртүчеләр керә.

Чыгарып куела торган щитлы конструкцияләр (штендерлар) - шәһәрдә предприятиеләр тарафыннан аларның эш сәгатьләрендә генә билгеләнә торган вакытлы реклама конструкцияләре.

Штендерлар ике яклы булырга тиеш, үз яктырткычлары булырга тиеш түгел, бер якның мәйданы 1,5 кв. метрдан артмаска тиеш.

Штендерлар җәяүлеләр зоналарында һәм тротуарларда предприятиегә керү урыныннан 5 м чигендә куела. Тротуар киңлеге кимендә ике метр булганда, җәяүлеләр юлына комачаулаучы штендерлар урнаштыру тыела, шулай ук машина юлыннан күренә торган штендерлар урнаштыру тыела.

4.2.2. Йөртелә торган реклама конструкцияләре - физик затлар тарафыннан техник чараларны кулланмыйча күчереп йөртеп була торган конструкцияләр.

Йөртелә торган реклама конструкцияләрен эксплуатацияләү җәяүлеләр зоналарында һәм тротуарларда рөхсәт ителә. Җәяүлеләр узуга комачаулаучы, шулай ук машина юлыннан кабул итүгә юнәлдерелгән йөртелә торган реклама конструкцияләрен куллану тыела.

4.2.3. Ваклап сату (урам) объектлары коймаларында (җәйге кафелар, күргәзмәләр, сәүдә мәйданнары коймалары), шулай ук башка вакытлы һәм даими киртәләрдәге реклама конструкцияләре объектларның сәнгатьчә бизәлешен тәэмин итәргә тиеш.

Әлеге объектларны аерым щитлар, йомшак бизәлеш яки тоташ тасма белән бизәргә тәкъдим ителә. Щит конструкцияләрен куллану очракларында, щитларның биеклеге киртәләрнең төп элементлары зурлыгыннан аларның 1/2 биеклегеннән артмаска тиеш.

Төзелеш объектлары киртәләрендә йорт салучылар төзелә торган объект турындагы мәгълүмат белән щит реклама урнаштырырга тиеш. Башка реклама мәгълүматын, шулай ук тышкы реклама һәм мәгълүматның башка чараларын урнаштыру рөхсәт ителми.

4.2.4. Һава киңлекләрендә урнаштырылган һава шарларында, аэростатларда, дирижабльләрдә вакытлы реклама конструкцияләре бәйрәм, тематик чаралар уздыру чорына вакытлы реклама бизәлеше булып тора.

4.2.5. Ваклап сату һәм җәмәгать туклануы предприятиеләре эше вакытына кулланыла торган лотокларда, арбаларда, киоскларда һәм зонтикларда куела торган вакытлы реклама конструкцияләре лотокларның, киоскларның, арбаларның һәм зонтикларның аерым өлешләрен пленкалы яисә буяулы материаллар белән каплаудан гыйбарәт.

4.2.6. Бәйрәм яисә башка мәгълүмат кампаниясенең дәвамлылыгы чикләнгән вакытка рөхсәт документациясен рәсмиләштерү шарты белән шулай ук стационар реклама конструкцияләре дә вакытлы реклама сыйфатында теркәлергә мөмкин. Күрсәтелгән вакыт узганнан соң бирелгән рөхсәт документациясенең гамәлдә булуы тәмамлана, реклама конструкциясе тулысынча сүтелә, ә аның урнаштыру урыны йөкләмәләрдән азат дип санала.

4.3. Муниципаль транспорттагы реклама.

4.3.1. Транспорт чараларын бары тик яки күбесенчә күчмә реклама конструкцияләре сыйфатында куллану тыела.

4.3.2. Үзләренең нинди дә булса затлар булуын күрсәтә торган аерым тамгаларның транспорт чараларында урнашуы реклама булмый.

4.3.3. Транспорт чараларында урнаштырылган реклама хәрәкәт иминлегенә куркыныч тудырырга, шул исәптән транспорт чаралары белән идарә итүче затларга һәм хәрәкәтнең

башка катнашучыларына күз күремен чикләргә тиеш түгел һәм техник регламентларның башка таләпләренә туры килергә тиеш.

4.3.4. Автомототранспорт чараларындагы (алга таба текст буенча - АМТЧ) реклама түбәндәге урыннарда гына урнаштырылырга мөмкин:

җиңел автомобильләр кузовының ян өслекләрендә, микроавтобусларда һәм автобусларда, троллейбусларда һәм трамвайларда - тәрәзә линиясенә кадәр;

йөк (йөк-пассажир) втомобильләренең (бортларында авыш ак полосалы автомобильләрдән тыш) кузовларның (шул исәптән фургоннарның), АМТЧка прицепларның һәм ярымприцепларның ян өслекләрендә;

мотоциклларның ягулык бакларында һәм инструмент әрҗәләре капкачында.

4.3.3. Реклама мәйданы АМТЧның буялган кузов детальләренең 50 процентыннан артмаска тиеш.

4.3.4. Түбәндәге АМТЧнда реклама урнаштыру тыела:

- техник регламентлары таләпләре белән билгеләнгән, билгеле бер төсле график буяулы махсус һәм оператив хезмәтләргә;

- куркыныч йөкләрне ташу өчен билгеләнгән;

- ян өслегендә диагональ буенча зәңгәр фонда ак полосалар урнашкан федераль почта элемтәсе;

- махсус яктылык һәм тавыш сигналлары белән җиһазландырылган.

4.3.5. Рөхсәт ителми:

- реклама максатларында АМТЧда АМТЧ җитештерүче заводта каралмаган тышкы яктылык приборларын урнаштырырга, шулай ук бу максатларда АМТЧда «Автомобильләрнең, автобусларның, троллейбусларның, тракторларның, прицепларның һәм ярымприцепларның тышкы яктылык приборлары. Саны, урнашуы, төсе, күрү почмаклары» ГОСТ 8769-75 Дәүләт стандартлары нигезендә урнаштырылган тышкы яктылык приборларын кулланырга;

- АМТЧна рәсеме, төсе, урнашу урыны буенча махсус һәм оператив хезмәтләрнең АМТЧндагы төсле график схемалары белән охшаш реклама ясарга;

- АМТЧга реклама төшерү өчен каплау һәм яктылык кайтаручы сыйфатка ия элементлар куллану:

- АМТЧна тышкы ут приборларын, борт номерларын, мәгълүмати язмаларны һәм символларны каплый торган реклама, шулай ук машина йөртүче урыныннан күрүне чикли торган реклама төшерергә.

4.3.6. АМТЧна реклама щитлары, табличкалар, яктылык таблолары урнаштыру Балтач муниципаль районының ЮХИДИ бүлеге белән килештеп башкарыла.

4.3.7. Җәмәгать транспорт чараларында тышкы реклама реклама урнаштыру өлкәсендә вәкаләтләренә ия булган органнар белән мәҗбүри килешенергә тиеш.

4.4. Реклама-тамаша чаралары.

Реклама-тамаша чаралары - бу катнашучыларга да, физик затларга - әлеге мәгълүматны кулланучыларга да йогынты ясый торган ачык акцияләр.

## 5. Реклама конструкцияләренә һәм тышкы мәгълүмат чараларына карата куела торган гомуми таләпләр

5.1. Биналарда, корылмаларда һәм башка объектларда урнашканда, реклама конструкцияләре һәм тышкы мәгълүмат чаралары бина, төзелеш, корылма архитектурасына туры килергә тиеш (тышкы мәгълүмат чараларын урнаштыру урыннары объект проекты яисә объектны реклама бизәлеше концепциясе белән билгеләнә) һәм шәһәрнең, мәйданнарның, биналарның, корылмаларның бердәм архитектур-сәнгать йөзен бозмаска тиеш.

5.2. Реклама конструкциясе бары тик реклама, социаль реклама тарату максатларында гына кулланылырга тиеш.

5.3. Реклама конструкцияләре һәм (яисә) тышкы мәгълүмат чаралары арасындагы ераклык бер-берсен визуаль рәвештә капларга тиеш булмаган янәшә урнашкан реклама конструкцияләрен исәпкә алып билгеләнә.

5.4. Реклама конструкцияләре аларда урнаштырылган сурәттән башка яки бозылган

сурәт белән файдаланыла алмый.

5.5. Реклама конструкцияләрен һәм тышкы мәгълүмат чараларын урнаштырганда, автомобиль юлларын һәм урамнарны карап тоту уңайлылыгын исәпкә алырга кирәк. Реклама конструкцияләре һәм тышкы мәгълүмат чаралары урамнарны һәм тротуарларны җыештыру өчен, шулай ук газоннарны чабу өчен киртәләр булдырырга тиеш түгел.

5.6. Реклама таратучы реклама конструкциясен яки тышкы мәгълүмат чараларын урнаштырганнан (сүткәннән) соң территорияне төзекләндерергә тиеш. Реклама конструкциясен аның нигезе белән бергә сүтәргә кирәк.

5.7. Караңгы вакытта щитлы реклама конструкцияләре тышкы яктылык чыганагы белән яктыртылырга тиеш.

5.8. Реклама конструкцияләре һәм аларның территориаль урнашуы техник регламентлар таләпләренә туры килергә тиеш.

Реклама конструкцияләренә һәм аларның территориаль урнашуына техник регламентлар булмаганда, төзелеш нормалары һәм кагыйдәләре, шулай ук дәүләт стандартлары белән билгеләнгән таләпләр кулланыла.

5.9. Реклама конструкцияләрен һәм тышкы мәгълүмат чараларын әзерләгәндә кулланыла торган материаллар заманча сыйфат таләпләренә җавап бирергә тиеш, аларны монтажлау расланган проект документациясеннән тайпылышсыз башкарылырга тиеш. Реклама конструкцияләре һәм тышкы мәгълүмат чаралары төзек хәлдә булырга тиеш.

5.10. Халыкның тормышы һәм сәламәтлеге өчен куркыныч реклама конструкцияләрен һәм тышкы мәгълүмат чараларын куллану рөхсәт ителми.

5.11. Җәяүлеләр зоналарында урнашкан күләмле пространстволы конструкцияләр рәвешендәге җайланмаларның техник һәм эстетик дәрәҗәсенә югары таләпләр куела. Күрсәтелгән җайланмаларның эчке яки тышкы яктылыгы булырга тиеш. Плакатны пыяла яки үтә күренмәле пленка белән сакларга киңәш ителә.

5.12. Аерым торучы щитлы җайланмалар, кагыйдә буларак, ике яклы вариантта башкарыла. Аерым торучы щитлы җайланмаларның фундаментлы нигезләре (блоклары) нигезне кара туфрак белән күмеп һәм газон үләне чәче, җир өсте тигезлегеннән түбәнрәк күмелергә тиеш Башкарма комитет белән килештереп, фундаментны инженерлык корылмасы - чәчәк түтәле яисә эскәмия рәвешендә хәл итәргә мөмкин.

5.13. Реклама конструкцияләре реклама таратучыны, контакт телефонын күрсәткән маркировкалы булырга тиеш.

**6. Реклама конструкцияләрен урнаштыру өлкәсендә вәкаләтләргә ия органнар**

6.1. Татарстан Республикасы Балтач район Советы:

- Балтач муниципаль районы территориясендә (алга таба - Район) реклама конструкцияләрен һәм тышкы мәгълүмат чараларын урнаштыруга карата гомуми мәҗбүри кагыйдәләрне һәм төп таләпләрне раслый.

6.2. Балтач район башкарма комитеты (алга таба - Башкарма комитет) турыдан-туры яисә үзе вәкаләт биргән органнар һәм вазыйфаи затлар исеменнән, шулай ук үзе төзи торган муниципаль учреждениеләр аша:

- Балтач муниципаль районының реклама-мәгълүмат бизәлеше өлкәсендә бердәм сәясәтне гамәлгә ашыра;

- Балтач муниципаль районы территориясендә тышкы реклама һәм мәгълүмат чараларын урнаштыру регламентын, Балтач муниципаль районы территориясендә реклама конструкцияләрен урнаштыруга типлаштырылган килешү формасын раслый;

- реклама конструкцияләрен урнаштыруга рөхсәт бирә;

- реклама конструкцияләрен һәм тышкы мәгълүмат чараларын урнаштыруга документлар карау процедурасын билгели;

- реклама конструкцияләрен һәм тышкы мәгълүмат чараларын урнаштыру урыннарын вәкаләтле органнар һәм оешмалар белән килештерә;

- реклама конструкцияләрен һәм тышкы мәгълүмат чараларын урнаштыру урыннары реестрын алып бару өчен тәртипне, форманы һәм вәкаләтле органнарны раслый;

- Балтач муниципаль районы территориясендә урнаштырыла торган реклама

конструкцияләрен һәм тышкы мәгълүмат чараларын инвентаризацияләү буенча эшчәнлекне оештыра;

- реклама конструкцияләрен һәм тышкы мәгълүмат чараларын урнаштыруга таләпләрнең үтәлешен контрольдә тота;

- Балтач муниципаль районын бәйрәм, юбилей даталарына бизәүнең, социаль реклама урнаштыруның муниципаль заказ бирүчесе булып тора;

- реклама конструкцияләре өчен бер типтагы башкаруда аукцион оештыра һәм район өчен социаль әһәмияткә ия булган реклама элементлары, стандарт булмаган реклама конструкцияләре урнаштырылганда конкурс оештыра;

- юридик затлар һәм шәхси эшкуарлар белән муниципаль милек объектларында реклама конструкцияләрен урнаштыруга шартнамәләр әзерләүне һәм төзүне тәэмин итә;

- муниципаль милек объектларында реклама конструкцияләрен урнаштыруга шартнамәләр шартларының үтәлешен контрольдә тота;

- Балтач муниципаль районы территориясендә тышкы реклама һәм мәгълүмат чараларын урнаштыру өлкәсендә муниципаль хокукый актлар проектларын эшли;

- район территориясендә урнаштырыла торган реклама конструкцияләрен инвентаризацияләү эшчәнлеген оештыра;

- эшче органнар, комиссияләр оештыруны, муниципаль милек объектларында тышкы реклама һәм мәгълүмат чараларын урнаштыру хокукына сатулар (торглар) уздыруны гамәлгә ашыра.

6.3. Әлеге Нигезләмәнең 6.2 пунктында каралган вәкаләтләрне үтәү өчен Татарстан район башкарма комитеты кирәк булганда комиссияләр, эшче төркемнәр төзергә мөмкин.

**7. Рөхсәт бирү тәртибе**

7.1. Реклама конструкциясе паспортын рәсмиләштерү түбәндәгечә башкарыла:

- алар буенча аукционнар үткәрелгән реклама конструкцияләре һәм аларны урнаштыру урыннары өчен - аукционнар үткәрү Комиссиясе беркетмәләре нигезендә;

- реклама конструкциясен муниципаль булмаган объектта яисә җирдә урнаштыру өчен - шартнамә нигезендә яисә милекченең яки күчемсез мөлкәтнең башка законлы хуҗасының әлеге мөлкәткә реклама конструкциясен кушуга ризалыгы нигезендә.

7.2. Дәүләт милкендәге яисә муниципаль милектәге җир кишәрлегендә, бинада яисә башка күчемсез мөлкәттә реклама конструкциясе урнаштыруга һәм эксплуатацияләүгә шартнамә төзү җирле үзидарә органнары яисә аларның вәкаләтле оешмалары тарафыннан Россия Федерациясе законнары нигезендә үткәрелә торган сатулар (аукцион яисә конкурс рәвешендә) нигезендә гамәлгә ашырыла. Сатулар (аукцион яисә конкурс) үткәрү формасы муниципаль берәмлекләрнең вәкиллекле органнары тарафыннан билгеләнә.

7.3. Муниципаль милектәге һәм җирле үзидарә органы белән реклама конструкциясе хуҗасы арасындагы шартнамә нигезендә реклама конструкциясе урнашкан җир кишәрлегендә, бинада яисә башка күчемсез мөлкәттә реклама конструкциясен урнаштыруга һәм эксплуатацияләүгә шартнамә төзү аукцион яисә конкурс реклама конструкциясен урнаштыруга һәм эксплуатацияләүгә шартнамәнең гамәлдә булу вакыты узгач уздырыла.

7.4. Реклама конструкциясен урнаштыру әлеге Нигезләмәнең 1 нче кушымтасында күрсәтелгән Рөхсәт кәгазе булганда рөхсәт ителә. .

Рөхсәттә реклама конструкциясе хуҗасы, реклама конструкциясе кушылган җир кишәрлеге, бина яисә башка күчемсез мөлкәт милекчесе, реклама конструкциясе тибы, аның мәгълүмат кырының мәйданы, реклама конструкциясе урнаштыру урыны, Рөхсәт кәгазе гамәлдә булу вакыты, Рөхсәт биргән орган, аның номеры һәм бирү датасы, башка белешмәләр күрсәтелә.

7.5. Рөхсәт башкарма комитет тарафыннан реклама конструкциясе беркетелә торган тиешле күчемсез мөлкәтнең милекчесе яки башка законлы хуҗасы яисә вәкаләтле органнар белән килештерү буенча реклама конструкциясе хуҗасының Рөхсәт бирү турында яисә аны бирүдән баш тарту турында карар кабул итү өчен кирәкле булган гаризасы нигезендә бирелә. Гариза формасы әлеге Нигезләмәнең 2 нче кушымтасында. .

7.6. Тышкы реклама тарату өлкәсендә өстенлекле урын биләгән затка күчемсез

мөлкәтнең милек формасына бәйсез рәвештә җир кишәрлегендә, бинада, башка күчемсез мөлкәттә реклама конструкциясе урнаштыруга Рөхсәт бирү рөхсәт ителми.

7.7. Рөхсәт бирелгән зат Башкарма комитетка әлеге реклама конструкциясенә карата өченче затларда хокуклар барлыкка килүнең барлык фактлары (реклама конструкциясен арендага бирү, реклама конструкциясен гади ширкәт шартнамәсе буенча кертем сыйфатында кертү, ышанычлы идарә шартнамәсе төзү, башка фактлар) турында хәбәр итәргә тиеш.

7.8. Витриналарда, киоскларда, лотокларда, сәүдә пунктларында, урамнарда тышкы рекламаны тарату өчен рөхсәт алу таләп ителми.

7.9. Рөхсәт алу өчен гаризага түбәндәгеләр теркәлә:

1) гариза бирүче турында мәгълүматлар

- физик зат - паспорт күчермәсе, салым органында исәпкә кую турында таныклык күчермәсе;

- юридик зат - юридик затны дәүләт теркәвенә алу турында таныклык күчермәсе, салым органында исәпкә кую турында таныклык күчермәсе;

- шәхси эшкуарга - паспорт күчермәсе, физик затны индивидуаль эшкуар буларак дәүләт теркәвенә алу турында таныклык күчермәсе, салым органында исәпкә кую турында таныклык күчермәсе;

2) әгәр мөрәҗәгать итүче тиешле күчемсез мөлкәтнең милекчесе яисә башка законлы хуҗасы булмаса, язма рәвештә яисә дәүләт һәм муниципаль хезмәт күрсәтүләрнең бердәм порталын һәм (яки) дәүләт һәм муниципаль хезмәт күрсәтүләрнең бердәм порталын кулланып, милекчесенең яисә тиешле күчемсез мөлкәтнең башка законлы хуҗасының әлеге мөлкәткә реклама конструкциясе кушылуга ризалыгын раслау;

3) тышкы реклама һәм мәгълүмат чарасы беркетелә торган мөлкәткә хокук билгели торган документлар:

- милек хокукын дәүләт теркәвенә алу турында таныклыкның яки тышкы реклама һәм мәгълүмат чарасы беркетелә торган мөлкәткә милек хокукын таныклаучы башка документның күчермәсе;

- тышкы реклама һәм мәгълүмат чарасы җир кишәрлегенә беркетелгән очракта, - бирелгән җирләрнең расланган чикләре белән җир кишәрлеген 1:500 масштабында топографик ысул белән төшерү күчермәсе; тышкы реклама һәм мәгълүмат чарасы бинага беркетелсә - бинага техник паспортның күчермәсе; әгәр тышкы реклама һәм мәгълүмат чарасы бинада аерым бүлмәгә беркетелсә, - бинага техник паспорттан өземтәнең күчермәсе яки бүлмәгә техник паспортның күчермәсе (булган очракта);

- гариза бирүче арендага алучы булса, - аренда шартнамәсе күчермәсе;

4) реклама конструкциясе тибы турында, урнаштыруның фаразланган урынының адресын һәм бәйлелеген күрсәтеп, белешмәләр;

5) реклама конструкциясен урнаштыруның фаразланган урынының фотографияләре (транспорт чараларында реклама урнаштырганда таләп ителми);

6) реклама конструкциясенең урнашу урынына бәйләп, масштабта һәм төстә башкарылган эскиз проекты;

7) Россия Федерациясе Салым кодексы нигезендә дәүләт пошлинасын түләү турындагы түләү йөкләмәсе (квитанция) күчермәсе

8) законда билгеләнгән тәртиптә рәсмиләштерелгән вәкилгә (вәкил булган очракта) ышанычнамә күчермәсе;

9) төзелә торган объектта яисә төзелеш киртәсендә тышкы рекламаны һәм мәгълүмат чараларын урнаштыру планлаштырылган очракта, төзелешкә рөхсәт күчермәсе;

10) Балтач муниципаль районы буенча ЮХИДИ бүлекчәсе белән килештерү турында белешмә күчермәсе.

Башкарма комитет гариза бирүчедән территориаль урнашуга, тышкы кыяфәтенә һәм реклама конструкциясенең техник параметрларына карамаучы документлар һәм белешмәләр тапшыруны, шулай ук дәүләт пошлинасыннан тыш, Рөхсәт кәгазен әзерләү, рәсмиләштерү, бирү һәм гамәлләр башкаруга рөхсәт бирүгә бәйле башка гамәлләр кылу өчен өстәмә түләүне таләп итәргә.

Башкарма комитет тиешле органнар белән рөхсәт бирү турында яисә аны бирүдән баш тарту турында карар кабул итү өчен кирәк булган килештерүне гамәлгә ашыра. Шул ук вакытта гариза бирүче мондый килештерүне мөстәкыйль рәвештә алырга һәм аны Башкарма комитетка тапшырырга хокуклы.

7.10. Рөхсәт бирү турында яисә аны бирүдән баш тарту турында карар кирәкле документларны кабул иткән көннән соң ике ай эчендә Башкарма комитет тарафыннан гариза бирүчегә җибәрелергә тиеш.

7.11. Рөхсәт бирүдән баш тарту турында карар дәлилләнгән һәм түбәндәге нигезләрдә кабул ителгән булырга тиеш:

1) реклама конструкциясе проектының һәм аны территориаль урнаштыруның техник регламент таләпләренә туры килмәве;

2) билгеләнгән урында реклама конструкциясен урнаштыруның генераль планга яисә территориаль планлаштыру схемасына туры килмәве;

3) транспорт хәрәкәте куркынычсызлыгы буенча норматив актлар таләпләрен бозу;

4) Балтач муниципаль районында төзелгән төзелешнең тышкы архитектур кыяфәтен бозу;

5) Россия Федерациясе халыкларының мәдәни мирас объектлары (тарих һәм мәдәният һәйкәлләре), аларны саклау һәм куллану турында Россия Федерациясе законнары таләпләрен бозу;

6) реклама конструкциясен урнаштыруга рөхсәт бирү (тышкы мәгълүмат чараларын урнаштыруны килештерү) турында гаризаны тиешенчә рәсмиләштермәү - гаризага имза куелмаган, гаризаның формасы белән каралган белешмәләр күрсәтелмәгән;

7) гаризага беркетелгән документларның гаризада күрсәтелгән документларга туры килмәве яки тиешле документлар булмаганда һәм Россия Федерациясе һәм Татарстан Республикасы законнарын башка бозулар булганда.

8) Россия Федерациясе бюджет системасы бюджетларына салымнар, җыемнар һәм башка түләүләр буенча бурычлар бар.

7.12. Рөхсәт Башкарма комитет тарафыннан һәр реклама конструкциясенә реклама конструкциясен урнаштыру һәм эксплуатацияләү өчен килешү гамәлдә булу вакытына, әмма 5 елдан да артмаган вакытка бирелә.

7.13. Башкарма комитет тарафыннан Рөхсәтне гамәлдән чыгару турында карар кабул ителергә мөмкин. Рөхсәтне гамәлдән чыгару турында карар түбәндәгечә кабул ителә:

1) Реклама конструкциясе хуҗасы тарафыннан Башкарма комитетка алга таба рөхсәт кәгазеннән файдаланудан баш тарту турында язма хәбәрнамә яисә дәүләт һәм муниципаль хезмәтләрнең бердәм порталын һәм (яки) дәүләт һәм муниципаль хезмәтләрнең региональ порталларын кулланып, электрон документ рәвешендә җибәрелгәннән соң бер ай эчендә;

2) Башкарма комитетка милекче яисә реклама конструкциясе урнаштырылган күчемсез мөлкәтнең башка законлы хуҗасы тарафыннан милекче яисә күчемсез мөлкәтнең башка законлы хуҗасы һәм реклама конструкциясе хуҗасы арасында төзелгән шартнамәнең туктатылуын раслый торган документ җибәрелгән вакыттан алып бер ай дәвамында;

3) Рөхсәт бирелгән көннән бер ел эчендә реклама конструкциясе урнаштырылмаган очракта;

4) реклама конструкциясе рекламаны, социаль рекламаны тарату максатларында кулланылмаган очракта;

5) Рөхсәт реклама конструкциясен урнаштыру һәм эксплуатацияләүгә шартнамә әлеге Нигезләмәдә билгеләнгән таләпләрне бозып төзегән затка бирелгән очракта яисә аукцион нәтиҗәләре Россия Федерациясе законнары нигезендә гамәлгә яраксыз дип танылган очракта.

7.14. Рөхсәт Россия Федерациясе законнарында билгеләнгән очракларда суд тәртибендә гамәлдә түгел дип танылырга мөмкин.

7.15. Рөхсәтне гамәлдән чыгару яки аны суд тәртибендә гамәлдә түгел дип тану очрагында, реклама конструкциясе хуҗасы яки милекче яисә әлеге конструкциясе урнаштырылган тиешле күчемсез мөлкәтнең башка законлы хуҗасы бер ай эчендә реклама

конструкциясен сүтәргә һәм мондый реклама конструкциясендә урнаштырылган мәгълүматны өч көн эчендә бетерергә тиеш.

7.16. Рөхсәтне гамәлдән чыгару яки аны гамәлдә түгел дип тану очрагында реклама конструкциясендә урнаштырылган мәгълүматны бетерү буенча бурычлар үтәлмәгәндә, милекче яки реклама конструкциясе кушылган күчемсез мөлкәтнең башка законлы хуҗасы мәгълүматны үз исәбенә бетерә.

7.17. Реклама конструкциясен рөхсәтсез урнаштыру (үз белдегең белән урнаштыру) рөхсәт ителми. Реклама конструкциясен рөхсәтсез урнаштырганда, ул вәкаләтле орган күрсәтмәсе нигезендә милекче яки рөхсәтсез урнаштырылган реклама конструкциясе беркетелгән күчемсез мөлкәтнең башка законлы хуҗасы тарафыннан сүтелергә тиеш.

Реклама конструкциясен сүтү бурычын үтәмәгән очракта Башкарма комитет судка яки арбитраж судына реклама конструкциясен сүтүне мәҗбүри рәвештә башкару турында гариза белән мөрәҗәгать итәргә хокуклы. Суд яки арбитраж суды тарафыннан реклама конструкциясен сүтүне мәҗбүри рәвештә башкару турында карар кабул ителгән очракта, аны сүтү, саклау яки кирәк булганда юк итү милекче яки реклама конструкциясе беркетелгән күчемсез мөлкәтнең башка законлы хуҗасы хисабына гамәлгә ашырыла. Милекче яки әлеге күчемсез мөлкәтнең башка законлы хуҗасы таләбе буенча реклама конструкциясе хуҗасы реклама конструкциясен сүтү, саклау яки кирәк булганда юк итү белән бәйле чыгымнарны капларга тиеш.

7.18. Халыкның иминлеген тәэмин итү, шулай ук бердәм архитектура-сәнгать йөзен саклау максатыннан реклама конструкцияләре теркәлергә тиеш. Реклама конструкциясен теркәү вакыты Рөхсәт бирелгән вакытка тигез.

Реклама конструкциясен теркәгәндә реклама эше рәсмиләштерелә.

7.19. Реклама эше формасы һәм белешмәләр җыю тәртибе Башкарма комитет җитәкчесе карары белән раслана.

7.20. Реклама эше ике нөсхәдә төзелә, аларның берсе башкарма комитетта сакланырга тиеш, икенчесе реклама конструкциясе хуҗасына тапшырыла.

**8. Балтач муниципаль районында реклама конструкциясен урнаштыру хокукына аукционны әзерләү һәм үткәрү тәртибе**

8.1. Аукцион предметы - муниципаль объектларда яки йөкләмәләрдән азат булган җирләрдә реклама конструкциясе урнаштыру хокукы.

8.2. Реклама конструкциясе урнаштыру хокукына аукцион реклама конструкциясе урнаштыру хокукы бәясе турындагы ябык формадагы тәкъдим белән ачык формада уздырыла.

8.3. Аукционны Татарстан Республикасы Балтач район башкарма комитеты оештыра.

Аукционны оештыручы аукционны әзерләгәндә һәм уздырганда Россия Федерациясе законнары нигезендә түбәндәге функцияләрне башкара:

- Комиссия составын билгели һәм раслый;

- реклама конструкциясен урнаштыру хокукына старт бәясеннән тыш, аукцион документларын билгели һәм раслый;

- аукцион документларын биргән өчен дәгъвачылар тарафыннан түләү күләмен, вакытын һәм шартларын билгели;

- аукционда катнашу өчен гаризалар (алга таба - Гаризалар) кабул итүнең урынын, башлану һәм тәмамлану вакытын , аукцион нәтиҗәләрен ясау урынын һәм вакытын билгели;

- аукцион предметы буенча аукцион җиңүчесе белән килешү төзи.

8.4. Комиссия:

- үз эшенең регламентын эшли һәм раслый;

- аукцион үткәрү турында массакүләм мәгълүмат чараларында мәгълүмат хәбәрен әзерләүне һәм бастырып чыгаруны оештыра;

- дәгъвачылардан Гаризалар һәм алар төзегән исемлек буенча беркетелгән документларны кабул итә;

- дәгъвачылар тарафыннан тапшырылган документларны рәсмиләштерүнең дөреслеген тикшерә һәм аларның Россия Федерациясе законнары таләпләренә һәм аукцион

үткәрү турында мәгълүмат хәбәрендә бастырылган исемлеккә туры килүен билгели;

- Гариза кергән саен Гаризалар кабул итү журналында исәп алып бара;

- дәгъвачыларны аукционда катнашучылар дип тану яисә Россия Федерациясенең гамәлдәге законнарында һәм әлеге Нигезләмәдә билгеләнгән нигезләрдә аукционда катнашуга кертүдән баш тарту турында карар кабул итә һәм дәгъвачыларга кабул ителгән карар турында хәбәр итә;

- дәгъвачылардан гариза биргән көнне яисә аукцион нәтиҗәләрен чыгарган көнне бирелә торган реклама конструкциясен урнаштыру хокукы бәясе турында тәкъдимнәр кабул итә;

- аукцион җиңүчесен билгели һәм аукцион нәтиҗәләре турында беркетмә рәсмиләштерә;

- аукционда җиңүчегә аның аукционда җиңүе турында хәбәр итә;

- аукцион нәтиҗәләре турында мәгълүмат хәбәрен әзерләүне һәм бастырып чыгаруны оештыра.

8.5. Дәгъвачы - аукционда катнашырга ризалыгын белдергән һәм Комиссиядә кирәкле аукцион документлары алган юридик зат яки шәхси эшкуар.

Аукционда катнашу өчен дәгъвачы (шәхсән яисә үзенең вәкаләтле вәкиле аша) Комиссиягә билгеләнгән вакытта аукцион оештыручы тарафыннан раслана торган форма буенча заявка һәм аукцион үткәрү турында мәгълүмат хәбәрендә бастырылган исемлек нигезендә башка документларны тәкъдим итә. Заявка һәм тәкъдим ителгән документлар исемлеге 2 (ике) нөсхәдә төзелә, берсе - Комиссиядә, икенчесе - дәгъвачыда кала.

Дәгъвачылар түләргә сәләтсез булырга, ликвидация процессында булырга, дәүләтсез (банкрот) дип танылган булырга тиеш түгел.

Милекләренә арест салынган юридик затлар һәм шәхси эшкуарлар һәм (яисә) икътисадый эшчәнлеге туктатылган затлар дәгъвачы була алмый.

8.6. Аукцион документлары - аукционны оештыручы тарафыннан раслана торган һәм аукцион предметы һәм аны үткәрү шартлары турында мәгълүмат булган документлар комплекты.

Дәгъвачыларга тапшырыла торган аукцион документлары составына түбәндәгеләр керә:

- исеме, аукцион предметы, аны уздыру урыны һәм вакыты турында мәгълүмат;

- оештыручы турында белешмәләр;

- реклама конструкциясе урнаштыру хокукының старт бәясе: старт бәясе күләмен билгеләү тәртибе Балтач муниципаль районы Советы карары нигезендә билгеләнә;

- дәгъвачылар Заявкасының үрнәге;

- дәгъвачылар тапшырырга тиешле документлар исемлеге һәм аларга таләпләр;

- дәгъвачылар Заявкаларын һәм беркетелгән документларның кабул итә башлау һәм төгәлләү даталары, кабул итү урыны һәм почта юлламалары өчен адрес;

- Заявканы кире алу тәртибе һәм вакыты;

- билгеләнгән вакыттан соң килгән Заявкаларның һәм документларның каралмавы турында кисәтү;

- аукционга йомгак ясау үткәреләчәк Комиссия утырышының датасы, урыны, вакыты һәм тәртибе;

- җиңүче һәм аукционны оештыручы арасында шартнамә (шартнамәләр) проекты;

- үткәрелгән аукцион нәтиҗәләре буенча барлыкка килә торган үзара йөкләмәләр һәм якларның җаваплылыгы турында кисәтү;

- шартнамә (шартнамәләр) имзаланырга тиешле вакыт.

Аукцион документларын алу өчен дәгъвачыга оештыручының исәп-хисап счетына түләү кертергә кирәк.

Түләү документын Комиссиягә тапшырырга.

Аукцион документларын биргән өчен түләү оештыручы тарафыннан аукцион уздыру чыгымнарын компенсацияләү өчен кирәкле күләмдә билгеләнә.

8.7. Заявка - аукцион документлары таләпләре нигезендә дәгъвачы әзерләгән

документлар комплекты.

Заявканы кире алу - Заявканы Комиссиягә биргәннән соң, дәгъвачының аукционда катнашудан баш тартуы.

Аукционда катнашырга теләк белдергән дәгъвачылар Комиссиягә түбәндәге документларны тапшыра:

- аукционда катнашуга заявка;

- теркәлү турында таныклык күчермәсен, төгәл юридик адресын, телефон номерын, факс номерын, юридик зат җитәкчесенең фамилиясен, исемен, атасының исемен яисә индивидуаль эшкуарның фамилиясен, исемен, атасының исемен, банк реквизитларын һәм гариза биргән вакытка Юридик затларның бердәм дәүләт реестрыннан яисә шәхси эшкуарларның бердәм дәүләт реестрыннан өземтәне кертеп, Дәгъвачы турында тулы белешмәләр;

- аерым, мөһер сугылган ябык конвертта тәкъдим ителә торган реклама урыннары пакетларының һәркайсы буенча реклама конструкциясе урнаштыру хокукы бәясе буенча тәкъдим кертелә.

8.8. Комиссия аукцион уздыру датасына кимендә 30 көн кала массакүләм мәгълүмат чараларына аукцион уздыру турында мәгълүмат хәбәре урнаштыра.

Мәгълүмат хәбәре үз эченә түбәндәгеләрне алырга тиеш:

- аукционның исеме һәм предметы, аны үткәрү урыны, датасы һәм вакыты;

- аукцион документларын алу ысулы, тәртибе һәм урыны;

- аукционда катнашу өчен Заявкалар бирүнең исемлеге, формасы һәм вакытлары;

- элемтә өчен телефоннар һәм Комиссиянең урнашу урыны.

8.9. Заявкалар кабул итү аукцион үткәрү турында мәгълүмат хәбәрендә игълан ителгән көннән башлап, 25 календарь көн эчендә гамәлгә ашырыла һәм Комиссия тарафыннан дәгъвачыларның Заявкаларын һәм документларын карау датасына кадәр бер календарь көннән дә соңга калмыйча тәмамлана.

Заявка Аңа беркетелгән документлар белән Комиссия секретаре тарафыннан һәр Заявкага номер биреп һәм документларны тапшыру датасын күрсәтеп, заявкаларны кабул итү журналында теркәлә. Заявканың һәр нөсхәсендә, аның номерын, кабул итү датасын һәм вакытын күрсәтеп, Заявканы кабул итү турында тамга куела.

Аукцион үткәрү турында мәгълүмат хәбәрендә күрсәтелгән кабул итү вакыты үткәннән соң кергән гаризалар, документларны кабул итүдән баш тарту турында тамга ясалган исемлек белән бергә, дәгъвачыларга яисә аларның вәкаләтле вәкилләренә имза куйдырып кире кайтарыла.

8.10. Аукцион үткәрү турында мәгълүмат хәбәрендә күрсәтелгән аукцион нәтиҗәләрен чыгарган көнне Комиссия дәгъвачыларның гаризаларын һәм документларын карый. Документларны карау нәтиҗәләре буенча Комиссия дәгъвачыларны аукционда катнашучылар дип тану яисә дәгъвачыларны аукционда катнашуга кертүдән баш тарту турында карар кабул итә.

Дәгъвачыларны аукционда катнашучылар дип тану турында Комиссия карары беркетмә белән рәсмиләштерелә.

Дәгъвачыларны аукционда катнашучылар дип тану турында беркетмәдә дәгъвачыларның исемнәрен (атамаларын) күрсәтеп, кабул ителгән Заявкалар исемлеге, кире алынган Заявкалар исемлеге, аукционда катнашучылар дип танылган дәгъвачыларның исемнәре (атамалары), шулай ук баш тартуның нигезләрен күрсәтеп, аукционда катнашу рөхсәт ителмәгән дәгъвачыларның исемнәре (атамалары) китерелә.

8.11. Аукционда катнашуга кертелмәгән дәгъвачыларга әлеге карарны беркетмә белән рәсмиләштерү датасыннан соңгы эш көненнән дә соңга калмыйча, аларга имза куйдырып, тиешле хәбәрнамәне бирү яисә бу хәбәрнамәне заказлы хат белән җибәрү юлы белән кабул ителгән карар турында хәбәр ителә.

Аукционда катнашудан баш тарту өчен нигезләр:

- аукционга нәтиҗәләр ясаган вакытка дәгъвачы аукцион документларында күрсәтелгән барлык документларны да тапшырмаган очракта;

- дәгъвачы билгеләнгән формадагы документларны тапшырмаган очракта;
- гамәлдәге законнарда каралган башка нигезләр буенча.

8.12. Аукционны узмаган дип тану өчен нигезләр булганда, Комиссия беркетмә белән рәсмиләштерелә торган тиешле карар кабул итә.

Аукционны узмаган дип тану өчен нигезләр:
- аукционда катнашу өчен бары тик бер дәгъвачы гына Заявка биргәндә;
- аукционда катнашучы дип бары тик бер дәгъвачы гына танылганда;
- аукционда катнашучыларның барысы тарафыннан күрсәтелгән бәя старт бәясеннән түбәнрәк булганда;
- гамәлдәге законнарда каралган башка нигезләр буенча.

8.13. Ябык формада реклама конструкциясе урнаштыру хокукы бәясе турындагы тәкъдимнәр белән аукцион түбәндәге тәртиптә уздырыла:

а). Заявка биргән көнне яки аукцион нәтиҗәләрен чыгарган көнне дәгъвачылар Комиссиягә ябыштырылган конвертта реклама конструкциясе урнаштыру хокукы бәясе турында тәкъдимнәр кертә.

б). Реклама конструкциясе урнаштыру хокукы бәясе турында тәкъдим булган конвертларны ачу алдыннан Комиссия аларның бөтенлеген тикшерә, бу аукцион нәтиҗәләре турындагы беркетмәдә теркәлә.

в). Конвертларны ачу Комиссиянең тулы вәкаләтле составы (аның хәлиткеч тавыш хокукына ия булган составының кимендә 2/3 е) булганда һәм аукционда катнашучылар катнашында үткәрелә; карар гади күпчелек тавыш белән кабул ителә, Комиссиянең һәр әгъзасы бер тавышка ия, тавышлар тигез булганда, Комиссия рәисе тавышы хәлиткеч булып тора.

г). Комиссия аукционда катнашучыларның реклама конструкциясе урнаштыру хокукы турындагы тәкъдимнәрен карый. Әлеге тәкъдимнәр рус телендә бәян ителергә һәм катнашучы (аның вәкаләтле вәкиле) тарафыннан имзаланырга тиеш. Бәясе сан белән һәм сүзләр белән күрсәтелә. Сан белән һәм сүзләр белән төрле бәяләр күрсәтелсә, Комиссия тарафыннан сүзләр белән күрсәтелгән бәя игътибарга алына. Старт бәясеннән түбәнрәк бәя булган тәкъдимнәр каралмый.

д). Комиссиянең аукцион нәтиҗәләре буенча җиңүчене билгеләү турындагы карары 2 (ике) нөсхәдә төзелә торган беркетмә белән рәсмиләштерелә, анда аукционда җиңүченең исеме (атамасы) һәм реклама конструкциясе урнаштыру хокукының тәкъдим ителгән бәясе күрсәтелә. Беркетмә җиңүченең реклама конструкциясе урнаштыруга шартнамә төзүгә хокукын раслаучы документ (алга таба - Шартнамә) булып тора.

Беркетмәгә аукцион нәтиҗәләрен чыгарган көнне аукцион уздыру комиссиясе әгъзалары имза куя һәм 3 (өч) көн эчендә аукцион җиңүчесенә җиңүче дип тану турында хәбәрнамә белән бергә җибәрелә.

8.14. Аукцион нәтиҗәләре турында мәгълүмат хәбәре аукцион нәтиҗәләре турындагы беркетмәгә имза куелган вакыттан алып 5 (биш) көн эчендә аукцион үткәрү турындагы мәгълүмат хәбәре бастырылган массакүләм мәгълүмат чараларында басыла.

8.15. Аукцион җиңүчесе җиңүче дип тану турында хәбәр ителгәннән соң 5 (биш) көн эчендә реклама конструкциясен оештыручының исәп-хисап счетына урнаштыру хокукын түләргә тиеш.

8.16. Аукцион җиңүчесе оештыручы белән Шартнамә төзи. Шартнамәне имзалау аукцион уздырылган көннән алып 15 (унбиш) эш көне эчендә башкарылырга тиеш.

Шартнамәне имзалау өчен җиңүче оештыручыга түбәндәге документларны тапшыра:
- аукцион нәтиҗәләре турында беркетмә;
- реклама конструкциясен урнаштыру хокукы өчен түләүне раслаучы түләү документы;
- дәүләт пошлинасын түләүне раслаучы түләү документы.

8.17. Аукцион җиңүчесе билгеләнгән вакытта Шартнамә төзүдән баш тартканда, аукцион нәтиҗәләре Комиссия тарафыннан гамәлдән чыгарыла.

## 9. Реклама конструкцияләрен һәм тышкы мәгълүмат чараларын урнаштыру һәм эксплуатацияләү

9.1. Реклама конструкциясен урнаштыру һәм эксплуатацияләү аның хуҗасы (кулланучысы) реклама конструкциясе беркетелә торган җир кишәрлеге, бина яки башка күчемсез мөлкәт милекчесе (хокук иясе) белән шартнамә төзеп гамәлгә ашырыла. Муниципаль милек объектларында реклама конструкциясен урнаштыруга һәм эксплуатацияләүгә шартнамә вәкаләтле Башкарма комитет тарафыннан төзелә.

9.2. Реклама конструкциясе беркетелә торган күчемсез мөлкәт милекче тарафыннан хуҗалык алып бару хокукында, оператив идарә итү хокукында яисә әйбер хокукыкында башка затка беркетелгән булса, реклама конструкциясен урнаштыруга һәм эксплуатацияләүгә шартнамә хуҗалык алып бару хокукына, оператив идарә итү хокукына яисә әлеге күчемсез мөлкәткә әйбер хокукыкына ия башка зат белән төзелә.

9.3. Реклама конструкциясе беркетелә торган күчемсез мөлкәт милекче тарафыннан ышанычлы идарәгә тапшырылган очракта, ышанычлы идарә итү шартнамәсе тиешле мөлкәт белән мондый гамәлләр кылуда ышанычлы идарәчене чикләмәсә, реклама конструкциясен урнаштыруга һәм эксплуатацияләүгә шартнамә ышанычлы идарәче белән төзелә.

9.4. Шартнамә гамәлдә булган чорда реклама конструкциясе хуҗасы реклама конструкциясе хуҗасының хокукларын гамәлгә ашыру, шул исәптән аны эксплуатацияләү, техник хезмәт күрсәтү һәм сүтү белән бәйле максатлар өчен әлеге мөлкәттән файдалану өлешендә күчемсез мөлкәткә тоткарлыксыз керә алу хокукына ия.

9.5. Реклама конструкциясе хуҗасы аны эксплуатацияли, куркынычсызлык техникасы нормаларын үтәп, аны төзек хәлдә тота һәм куркынычсызлык кагыйдәләрен бозган өчен һәм шуңа бәйле рәвештә килеп чыккан төзексезлекләр һәм (яисә) авария хәлләре өчен җавап тота.

9.6. Реклама конструкциясе яки тышкы мәгълүмат чарасы хуҗасы реклама конструкциясенең килештерелгән проект документациясенә өстәмәләр яки үзгәрешләр кертү хокукына ия түгел.

9.7. Реклама конструкциясе хуҗасы реклама конструкциясен рөхсәтсез урнаштырган очракта, рөхсәтне гамәлдән чыгару яки аны суд тәртибендә гамәлдә түгел дип тану очрагында, рөхсәтнең гамәлдә булу вакыты чыкканда, реклама конструкциясен урнаштыруга шартнамәне өзүгәндә, үз исәбенә реклама конструкциясен сүтәргә, шулай ук аларны эксплуатацияләүгә бәйле рәвештә барлыкка килгән барлык кимчелекләрне юк итәргә тиеш.

9.8. Реклама конструкциясе хуҗасы вәкаләтле органнарның реклама конструкциясенең техник халәтендәге һәм тышкы кыяфәтендәге җитешсезлекләрне бетерү зарурлыгы белән бәйле таләпләрен үтәргә тиеш.

9.9. Техник регламентлар үз көченә кергәнче, реклама конструкцияләрен урнаштыру «Автомобиль юлларында һәм шәһәр һәм авыл җирлекләре территорияләрендә тышкы реклама» ГОСТ Р 52044-2003 дәүләт стандарты нигезендә гамәлгә ашырыла.

9.10. Проект документлары гамәлдәге техник регламентлар, дәүләт стандартлары һәм башка тармак һәм ведомство норматив документлары нигезендә башкарылырга тиеш.

Реклама конструкцияләрен урнаштыру һәм эксплуатацияләү буенча монтаж-төзелеш һәм электромонтаж эшләре әлеге эшләрне башкаруга лицензиясе булган оешмалар тарафыннан проект документлары нигезендә башкарыла. Башкарылган эшләр район администрациясе белән берлектә реклама конструкциясе милекчесе тарафыннан кабул ителә.

9.11. Проект һәм рөхсәт документларында тиешле таләпләр булган очракта биналарда һәм корылмаларда реклама конструкцияләрен монтажлау баланста тотучы вәкилләр катнашында башкарыла.

9.12. Реклама конструкцияләрен урнаштыру эшләрен башкарганда түбәндәге документлар кирәк:

Рөхсәт;

электр челтәрләренә тоташуга рөхсәт;

реклама конструкциясен урнаштыруга шартнамә.

9.13. Реклама таратучының реклама конструкциясе буенча проект документларына өстәмәләр һәм үзгәрешләр кертү хокукы юк.

9.14. Реклама таратучы реклама конструкциясе урнаштырылганнан соң 15 көннән дә

соңга калмыйча 10 метр радиуста якындагы территорияне һәм объектны төзекләндерергә тиеш.

9.15. Реклама таратучы куркынычсызлык кагыйдәләрен бозган, шулай ук проект карарларын, реклама конструкциясен монтажлау һәм эксплуатацияләү шартларын бозган өчен барлыкка килгән төзексезлекләр һәм авария хәлләре өчен җаваплы. Реклама таратучы реклама конструкциясен урнаштыруга шартнамә гамәлдә булу вакыты тәмамланганнан соң реклама конструкциясен сүтәргә һәм реклама конструкциясе урнаштыруга кадәр булган халәткә китереп, тулысынча төзекләндерергә тиеш.

## 10. Рөхсәтсез урнаштырылган реклама конструкцияләрен сүтү

10.1. Реклама конструкциясен рөхсәтсез урнаштыру (үз белдегең белән урнаштыру) рөхсәт ителми. Яңа реклама конструкциясе рөхсәтсез куелса, ул вәкаләтле орган күрсәтмәсе нигезендә сүтелергә тиеш.

10.2. Рөхсәтсез куелган реклама конструкциясенең хуҗасы билгесез булган очракта, аны сүтү район Башлыгының хокукый акты нигезендә гамәлгә ашырыла.

## 11. Нигезләмә таләпләрен бозган өчен җаваплылык

Юридик затлар һәм шәхси эшкуарлар Россия Федерациясе законнары нигезендә реклама конструкцияләрен урнаштыру таләпләрен бозган өчен җаваплы.

Нигезләмәгә 1 нче кушымта

**РӨХСӘТ**

___________________________________________________ адрес буенча урнашкан _____________________________________________ 20___ елның _______________ ______ номерлы тышкы реклама чарасы паспорты нигезендә тиешле санда һәм размерда реклама конструкцияләрен урнаштыруга ___________________________ бирелде.

Рөхсәт бирелде: 5 елга

*Рөхсәттә реклама конструкциясе хуҗасы, реклама конструкциясе кушылган җир кишәрлеге, бина яисә башка күчемсез мөлкәт милекчесе, реклама конструкциясе тибы, аның мәгълүмат кырының мәйданы, реклама конструкциясе урнаштыру урыны, Рөхсәт кәгазе гамәлдә булу вакыты, Рөхсәт биргән орган, аның номеры һәм бирү датасы, башка белешмәләр күрсәтелә.*

Балтач район башкарма комитеты
җитәкчесе Ф.И.О.

Балтач район башкарма комитетының
төзелеш, архитектура һәм
торак-коммуналь хуҗалык бүлеге
башлыгы Ф. И. О.

Балтач район башкарма комитеты җитәкчесе
___________________________________
___________________________________
___________________________________
___________________________________
_______________________ ____ яшәүче
___________________________________
___________________________________
___________________________________

Оешманың юридик адресы:
___________________________________
___________________________________
___________________________________
___________________________________

Телефон_________ ________________
e-mail____________________________
факс_________ ____________________

**Гариза**

Сездән ___________________ _________________________________________________________

_____________________________________________________________________________________

_____________________________________________________________________________________

_____________________________________________________________________________________

_________________________________________________________________________ сорыйм.

Имза _______________________

Дата _____________________